| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Исполнительный комитет<br>Чалпинского сельского поселения<br>Азнакаевского<br>муниципального района | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Азнакай муниципаль районы<br>Чалпы авыл жирлеге<br>башкарма комитеты |
|---|---|---|
| ул. Центральная, д.39, с. Чалпы, 423324<br>Тел. (8-5592) 35-5-46,<br>факс (8-5592) 35-5-46<br>Chal.Azn@tatar.ru | | Үзәк урам, 39, Чалпы авылы, 423324<br>Тел. (8-5592) 35-5-46,<br>факс (8-5592)35-5-46<br>Chal.Azn@tatar.ru |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» апрель 2025 ел. № 44

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Башкарма комитетының «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге территориясендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау буенча муниципаль программа турында» 2022 елның 06 октябрендәге 19 номерлы карарының (01.11.2024 №40 үзгәрешләр белән) үз көчен югалтуын тану хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге башкарма комитетына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турындагы килешүне вакытыннан алда өзү турында 2025 елның 10 гыйнварындагы килешүне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Башкарма комитетының «2023-2025елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге территориясендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау буенча муниципаль программа турында» 2022 елның 06 октябрендәге 19 номерлы карарының (01.11.2024 №40 үзгәрешләр белән) карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны http//pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда халыкка җиткерергә һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http//Aznakayevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башлык: А.М.Мөхәмәтшин